ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 8 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; 2011, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 5; 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 78 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2025, № 56 (I өлеш), № 75 (I өлеш); 2026, № 1 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3. Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан башкасы каралмаган булса, әлеге Законның 14 статьясындагы 1 өлешендә каралган финанс ярдәме акцизлы товарлар, моңа тонусны күтәрә торган эчемлекләрдән кала шикәрле эчемлекләр керми, җитештерүне һәм (яисә) реализацияләүне, шулай ук файдалы казылмалар, гомумтаралган файдалы казылмалардан һәм эчәргә яраклы минераль сулардан тыш, чыгаруны һәм (яисә) реализацияләүне гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшкуарлык субъектларына күрсәтелә алмый.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2026 ел, 19 июнь
№ 39-ТРЗ